МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.03.2015 г.Казань № 134

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга яраштыру максатында, һәм шулай ук мониторинг нәтиҗәләрен исәпкә алып **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган түбәндә теркәлгән үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2014 елның 8 августындагы 289нчы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Административ регламент) .

2. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә (Т.А.Апаев) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне министр урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы
боерыгы белән расланган

19.03.2015 № 134

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 августындагы 277нче боерыгы белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

Административ регламентның 2 бүлеге 2.5 пунктында:

1 подпунктта («Стандарт таләбе эчтәлеге» графасы):

«б» подпунктын юкка чыгарырга;

«в – ж» подпунктларын «б – е» подпунктлары дип санарга;

2 подпунктта («Стандарт таләбе эчтәлеге» графасы):

«б» подпунктын яңа редакциядә бирергә:

«б) 1 пунктның «б», «в», «г», «д» подпунктларында күрсәтелгән мәгълүмат кергән документлар күчермәләре;»;

түбәндәге эчтәлектәге «в» подпункты белән тулыландырырга:

«в) кәгазь формадагы гамәлдәге лицензиянең төп нөсхәсен яки электрон имза куелган электрон документ шәкелендәге лицензияне;»;

«в» подпунктын «г» подпункты дип санарга;

3 подпунктта («Стандарт таләбе эчтәлеге» графасы) «б» подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«б) кәгазь формадагы гамәлдәге лицензиянең төп нөсхәсен яки электрон имза куелган электрон документ шәкелендәге лицензияне;»;

Административ регламентның 2 бүлеге 2.10 пунктын («Стандарт таләбе эчтәлеге») түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү түләүле нигездә башкарыла.

Дәүләт пошлинасы:

лицензия бирү - 7500 сум;

лицензиянең барлыгын раслый торган документны һәм (яки) шундый документка кушымтаны лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары турында өстәмә мәгълүмат кертү зарурлыгына бәйле рәвештә яңадан рәсмиләштерү - 3500 сум;

лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту - 750 сум;

лицензиянең барлыгын раслый торган документны һәм (яки) шундый документка кушымтаны башка очракларда яңадан рәсмиләштерү – 750 сум;

лицензия дубликатын бирү - 750 сум.

Түләүне алучы:

Татарстан Республикасы буенча ФКИ (ТР Икътисад министрлыгы)

Түләүне алучының реквизитлары:

Казан ш. Россия Банкының ТР Милли Банкының Дәүләт исәп-хисап-касса үзәге

БИК 049205001

ИНН 1655141501

КПП 165501001

ОКТМО 92701000

Исәп-хисап счеты 40101810800000010001

Бюджет классификациясе коды 70210807082011000110.

Лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бушлай бирелә.»;

Административ регламентның 2 бүлеге 2.15 пунктында:

«Стандарт таләбе эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

документларны кабул итү һәм карау срокларының үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогының үтәлеше;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозу прецедентларының (нигезле шикаятьләрнең) булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең уңайлыгы-якынлыгы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;

белгечләрнең, һәм шулай ук гариза бирүчеләрнең документларын кабул итү башкарыла торган бүлмәләрнең тиешле санда булуы;

Миниистрлыкның рәсми сайтында, Интернет челтәрендә, мәгълүмат такталарында дәүләт хезмәте күрсәтүнең сроклары, тәртибе, ысуллары турында тулы мәгълүматның булуы;

гаризаны электрон формада бирә алу мөмкинлеге;

гаризаны һәм документларны электрон документ формасында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша тапшырганда, гариза бирүченең хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша ала алу мөмкинлеге (ул гамәлгә ашырылганда).

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда бүлек белгече белән гариза бирүче арасында дүрт тапкыр үзара аралашу (гариза тапшыру, документар тикшерү актын имзалау, күчмә тикшерү актын имзалау, лицензия алу) күздә тотыла. Үзара аралашуның дәвамлылыгы Регламентта билгеләнә.»;

«Дәүләт хезмәте яки таләбен җайга салучы норматив акт» графасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«ТР МКның 880 санлы Карарының 2.4 пункты»;

Административ регламентның 2 бүлеге 2.17 пунктын («Стандарт таләбе эчтәлеге» графасы) түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru) лицензия алуга (яңадан рәсмиләштерүгә), лицензиянең күчермәсен, дубликатын алуга гаризаны электрон формада бирү процедурасы гамәлгә ашырылды.

Лицензияне электрон документ шәкелендә алу процедурасы (ул гамәлгә ашырылганда) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http://uslugi.tatar.ru) аша башкарыла»;

Административ регламентның 3 бүлеге атамасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада башкару үзенчәлекләре, һәм шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә башкару үзенчәлекләре»;

Административ регламентның 3.1.1 пункты 1 подпунктын: «, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру буенча;» сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 3.2 пункты атамасын «, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру буенча» сүзләре белән тулыландырырга;

Административ регламентның 3.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы буенча, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүнең башка сораулары буенча да.»;

Административ регламентның 3 бүлеге 3.3.17 подпунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга лицензияне, лицензия кушымтасын тапшыра.

Әгәр лицензия алу турындагы гаризада лицензияне электрон документ формасында алу зарурлыгы күрсәтелгән булса, лицензиягә дәгъва кылучыга

лицензияне, лицензия кушымтасын электрон имзасы булган электрон документ шәкелендә юллый.

Лицензияне электрон документ шәкелендә алу процедурасы (ул гамәлгә ашырылганда) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http://uslugi.tatar.ru) аша башкарыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

лицензия, лицензия кушымтасын тапшыру – 15 минут эчендә, чират тәртибендә, гариза бирүче килгән көнне;

лицензияне электрон документ шәкелендә юллау – әлеге Регламентның 3.3.16 подпунктында каралган процедура гамәлгә ашырылганнан соң, бер көн дәвамында.

Процедура нәтиҗәсе: тапшырылган яки юлланган лицензия, лицензия кушымтасы.»;

Административ регламентка Кушымада (белешмә) Г.Н.Фәсхиев вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бирергә: «Сәнәгать бүлеге башлыгы».